КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 ноябрь г.Казань № 866

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.4 бүлекнең 4.4.2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.2. Социаль хезмәтләр күрсәтү вакыты 6 ай вакыт белән ике елга 1 тапкыр тәшкил итә.»;

Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3. | Социаль-психологик хезмәтләр күрсәтү | | | |
| 3.1. | Социаль-психологик консультация үткәрү, шул исәптән гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга эчке проблемаларын, шәхесара бәйләнеш проблемаларын хәл итүдә квалификацияле ярдәм күрсәтү, социаль-психологик проблемаларны кисәтү һәм җиңеп чыгу, шул исәптән бу проблемаларны хәл итү өчен эчке ресурсларны мобилизацияләү юлы белән. Эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлап алу, эшкә урнашу, һөнәри белем алу максатларында һөнәри юнәлеш бирү турында мәгълүмат һәм консультация бирү | консультацияләр | социаль хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |
| 3.2. | Психологик ярдәм һәм булышлык күрсәтү, шул исәптән даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ булган инвалидларны өйдә карауны гамәлгә ашыручы гражданнарга | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучы шәхесе үзенчәлекләре җыелмасын тикшерү, тереклек эшчәнлегенең бозылган өлкәләрен компенсацияләү яки тергезү шартларын билгеләү, социаль-психологик ярдәм чаралары исемлеген эшләү, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның һөнәри мәнфәгатьләрен, омтылышларын, сәләтләрен ачыклау өчен һөнәри юнәлешне билгеләү диагностикасын үткәрү; | чаралар комплексы | социаль хезмәт күрсәтү чорында 3 тапкыр |
| | | социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга эмоциональ хәлендәге һәм үз-үзен тотышындагы тайпылышларны бетерүгә яки киметүгә формалаштыруга юнәлдерелгән | курслар | социаль хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | тернәкләндерү чараларын үткәрү, социаль-психологик проблемаларны хәл итү, универсаль адаптацион психологик күнекмәләрне (коммуникатив, үз-үзен тикшерүдә тоту, үз-үзен җайга салу, стрессларга бирешмәүчәнлек һ.б.) үстерү, белем алуга һәм эшкә урнашуга карата мотивациясен үстерү һәм күз аллауларын дөрес юнәлештә үзгәртү, төркемнәрдә (7 кешегә кадәр) яки индивидуаль рәвештә (диагностика нәтиҗәләре буенча) яңа шартларга адаптацияләнү өчен шәхси алшартлар формалаштыру; | | |
| | | даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ булган инвалидларны (инвалид балаларны) өйдә карауны гамәлгә ашыручы гражданга психологик ярдәм һәм булышлык күрсәтү | курслар | социаль хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |

Бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтаның «Сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәре, тасвирламасы, социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү күләмнәре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәре, тасвирламасы, социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү күләмнәре

| Т/с | Социаль хезмәт күрсәтү исеме | Социаль хезмәт күрсәтү тасвирламасы | Социаль хезмәт күрсәтү күләме | |
|---|---|---|---|---|
| | | | үлчәү берәмлеге | күрсәтү ешлыгы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Социаль-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү | | | |
| 1.2. | Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мәйданнар бирү | Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мәйданнар бирү (социаль хезмәтләр күрсәтүдән 1 файдаланучыга) | кв.метр | социаль хезмәт күрсәтү чорында 18 кв.метр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 2. | Социаль-медицина хезмәтләре күрсәтү | | | |
| 2.1. | Адаптив физик культура буенча дәресләр үткәрү | Компенсатор күнекмәләрен формалаштыруга юнәлдерелгән спорт-савыктыру характерындагы чараларны оештыру һәм үткәрү; тулы канлы тормыш белән яшәүгә комачаулый торган физик һәм психологик проблемаларны җиңеп чыгу | дәресләр | социаль хезмәт күрсәтү чорында 24 тапкыр |
| 3. | Социаль-психологик хезмәтләр күрсәтү | | | |
| 3.1. | Социаль-психологик консультацияләр үткәрү, шул исәптән гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга шәхеснең эчке проблемаларын, шәхесара бәйләнешләр проблемаларын хәл итүдә квалификацияле ярдәм күрсәтү, социаль-психологик проблемаларны кисәтү һәм җиңеп чыгу, бу проблемаларны хәл итү өчен эчке ресурсларны мобилизацияләү, эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлап алу, эшкә урнашу, һөнәри белем алу максатларында һөнәри юнәлеш бирү турында мәгълүмат һәм консультация бирү | консультацияләр | социаль хезмәт күрсәтү чорында 1 тапкыр |
| 3.2. | Психологик ярдәм һәм булышлык күрсәтү, шул исәптән даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ булган инвалидларны (инвалид балаларны) өйдә карауны гамәлгә ашыручы гражданнарга | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының шәхесе үзенчәлекләре җыелмасын тикшерү, тереклек эшчәнлегенең бозылган өлкәләрен компенсацияләү яки тергезү шартларын билгеләү, социаль-психологик ярдәм күрсәтү чаралары исемлеген эшләү, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның һөнәри мәнфәгатьләрен, омтылышларын, сәләтләрен ачыклау өчен һөнәри юнәлешне билгеләү диагностикасын үткәрү; | чаралар комплексы | социаль хезмәт күрсәтү чорында 3 тапкыр |
| | | социаль хезмәтләр күрсә- | курслар | социаль хезмәт күрсәтү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | түдән файдаланучыга эмоциональ хәлендәге һәм үз-үзен тотышындагы тайпылышларны бетерүгә яки киметүгә юнәлдерелгән тернәкләндерү чараларын үткәрү, социаль-психологик проблемаларны хәл итү, универсаль адаптацион психологик күнекмәләрне (коммуникатив, кешенең үз-үзен тикшерүдә тоту, үз-үзен җайга салу стрессларга бирешмәүчәнлек һ.б.) үстерү, белем алуга һәм эшкә урнашуга карата мотивациясен үстерү һәм күз аллауларын дөрес юнәлештә үзгәртү, төркемнәрдә (7 кешегә кадәр) яки индивидуаль рәвештә (диагностика нәтиҗәләре буенча) яңа шартларга адаптацияләнү өчен шәхси алшартлар формалаштыру; | | чорында 1 тапкыр |
| | | даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ булган инваладларны (инвалид балаларны) өйдә карауны гамәлгә ашыручы гражданга психологик ярдәм һәм булышлык күрсәтү | курслар | социаль хезмәт күрсәтү чорында1 тапкыр |
| 4. | Социаль-педагогик хезмәтләр күрсәтү | | | |
| 4.1. | Социаль-педагогик коррекцияләү, диагностика һәм консультацияләр үткәрүне кертеп | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга социаль-көнкүреш һәм социаль-мохит диагностикасын үткәрү | чаралар комплексы | социаль хезмәт күрсәтү чорында 3 тапкыр |
| 4.2. | Буш вакытны оештыру | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар белән бәйрәмнәр, экскурсияләр, концертларга бару (иҗат коллективларын чакыру), спорт ярышларын һәм бәйрәмнәрен оештыру һәм үткәрү | чаралар | социаль хезмәт күрсәтү чорында айга 1 тапкыр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Социаль-хезмәт хезмәтләре күрсәтү | | | |
| 5.1. | Хезмәт мөмкинлекләреннән файдалану һәм алар үзләштерә ала торган һөнәри күнекмәләргә өйрәтү чараларын үткәрү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыны ул булдыра ала торган һөнәри күнекмәләргә өйрәтү:<br>компьютер белеме нигезләренә өйрәтү;<br>юнәлешләрнең берсе буенча (бәйләү, үрү (макраме), кисү һәм тегү һ.б.) һөнәр алганга кадәр әзерләү | дәресләр (сәгать)<br>дәресләр (сәгать) | социаль хезмәт күрсәтү чорында 96 сәгать<br>социаль хезмәт күрсәтү чорында 96 сәгать |
| 6. | Социаль-хокукый хезмәтләр күрсәтү | | | |
| 6.1. | Юридик хезмәтләр күрсәтүдән файдалануда ярдәм итү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга (аның законлы вәкиленә) түләүсез юридик ярдәм алу хокукларын һәм механизмын аңлату; социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыга (аның законлы вәкиленә) социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының үз мәнфәгатьләре яклану, социаль хезмәт күрсәтелү, шулай ук социаль ярдәм чаралары күрсәтелү, тернәкләндерү һәм социаль интеграцияләнү, медицина-социаль экспертиза узу һәм инвалидлык билгеләнү хокукына бәйле булган мәсьәләләр буенча консультация оештыру (консультация бирү) | консультацияләр | социаль хезмәт күрсәтү чорында 2 тапкыр |
| 7. | Тереклек эшчәнлекләре чикләнгән социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларында хезмәтләр күрсәтү | | | |
| 7.1. | Инвалидларны (инвалид балаларны) тернәкләндерүнең техник чараларыннан файдаланырга өйрәтү | Тернәкләндерүнең техник чараларыннан мөстәкыйль файдалану буенча инвалидларның (инвалид балаларның) гамәли күнекмәләрен арттыру буенча дәресләр үткәрү: | | |
| | | төркемнәрдә (7 кешегә кадәр) яки индивидуаль рәвештә (күрсәткечләр буенча) GPS-навигациядән файдаланырга | дәресләр | социаль хезмәт күрсәтү чорында 48 тапкыр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | өйрәтү; | | |
| | | төркемнәрдә (7 кешегә кадәр) яки индивидуаль рәвештә (күрсәткечләр буенча) Брайль системасына өйрәтү | дәресләр | социаль хезмәт күрсәтү чорында 96 тапкыр |
| 7.2. | Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль-тернәкләндерү чараларын үткәрү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларны төркемнәрдә (7 кешегә кадәр) яки индивидуаль рәвештә (күрсәткечләр буенча) ориентирлашуга өйрәтү | дәресләр | социаль хезмәт күрсәтү чорында 96 көн |
| 7.3. | Үз-үзенә хезмәт күрсәтү, көнкүрештә һәм җәмәгать урыннарында үз-үзен тоту күнекмәләренә өйрәтү | Социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыны түбәндәгеләргә өйрәтү:<br>йорт эшләренә;<br><br>көнкүреш электр приборларыннан, тифлотехник һәм көнкүреш техникасыннан файдалану нигезләренә | <br><br><br>дәресләр<br><br>дәресләр | <br><br><br>социаль хезмәт күрсәтү чорында 24 тапкыр<br>социаль хезмәт күрсәтү чорында 24 тапкыр». |

2. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин